| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>**ЛАШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** | | **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>ЧЕРЕМШАНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** |
|---|---|---|
| 423110, Лашман авылы, Советлар урамы,55А йорт<br>Телефон (84396)2-92-35<br>Факс (84396) 2-92-35<br>Email: Lash.Cmn2@tatar.ru | | 423110. село Лашманка, ул.Советская, д.55А<br>Телефон (84396) 2-92-35<br>Факс (84396) 2-92-35<br>Email: Lash.Cmn2@tatar.ru |


**15 июль 2025 ел** **№ 8**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге территориясендә терекөмешле эшкәртелгән лампаларны җыюны оештыру тәртибе турында» 2017 елның 29 маендагы 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2024 елның 19 мартындагы 329 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары белән тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә эш итү кагыйдәләрен раслау турында» 2314 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге территориясендә терекөмешле эшкәртелгән лампаларны җыюны оештыру тәртибе турында» 2017 елның 29 маендагы 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «Терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында кулланучыларга мәгълүмат бирү әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән Лашман авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла».

2. Әлеге карарны рәсми хокукый порталда бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) (pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Лашман авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкчесе: С.Х.Гыйльманова